МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.03.2017 г. Казань № под-371/17

Татарстан Республикасы татар теле һәм
әдәбияты укытучылары арасында
дәрес эшкәртмәләре бәйгесе уздыру турында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 12.12.2016 елгы 2383/16 санлы боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасында 2030 елга кадәр милли мәгариф үсеше Концепциясе»н гамәлгә кую планының 4.42 пунктын һәм 06.07.2016 елгы 1326/16 санлы боерык белән расланган «2016-2017 уку елына Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында татар теле һәм әдәбияты укытуны камилләштерү юл картасы»ның 3.7 пунктын гамәлгә ашыру, педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын арттыру, белем бирүдә федераль дәүләт стандартларын гамәлгә куюга әзерлеген активлаштыру, талантлы хезмәткәрләрне ачыклау максатында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтына (ректоры Р.Р.Бәдриева) Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучылары арасында дәрес эшкәртмәләре бәйгесе оештырырга.

2. Расларга:

2.1.«Милли мәгариф: заманча татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә танып белү эшчәнлеген оештыру» республикакүләм дәрес эшкәртмәләре бәйгесе нигезләмәсе;

2.2.«Милли мәгариф: заманча татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә танып белү эшчәнлеген оештыру» республикакүләм дәрес эшкәртмәләре бәйгесенең эксперт төркеме;

2.3. «Милли мәгариф: заманча татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә танып белү эшчәнлеген оештыру» республикакүләм дәрес эшкәртмәләре бәйгесенең оештыру комитеты.

3. Боерыкны Татарстан Республикасының муниципаль мәгариф бүлекләренә һәм идарәләренә җиткерергә.

4. Боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.Р.Мөхәммәтовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр Э.Н.Фәттахов

Документ создан в электронной форме. № под-371/17 от 09.03.2017. Исполнитель: Гайфуллина Л.А.
Страница 1 из 6. Страница создана: 09.03.2017 16:08
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының
2017 елның __09__ мартыннан гамәлгә кергән
№ __под-371/17__боерыгы белән расланды

**«Милли мәгариф: заманча татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә танып белү эшчәнлеген оештыру» республикакүләм дәрес эшкәртмәләре бәйгесе**

# НИГЕЗЛӘМӘСЕ

## I. Гомуми мәгълүмат

Әлеге нигезләмә бәйгенең статусын, үткәрүнең максатын, бурычларын билгели; бәйгене оештыру, үткәрү, йомгаклау, бүләкләү тәртибен рәсмиләштерә.

## II. Бәйгенең статусы

Бәйге республика күләмендә уздырыла. Ул 2016 елның 12 декабрендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2383/16 боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасында 2030 елга кадәр милли мәгариф үсеше Концепциясе»н гамәлгә кую планының 4.42 пункты куйган бурычны тормышка ашыру һәм 2016 елның 6 июлендә 1326/16 боерык белән расланган «2016-2017 уку елына Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында татар теле һәм әдәбияты укытуны камилләштерү юл картасы»ның 3.7 пункты нигезендә чара буларак уздырыла.

## III. Бәйгенең максаты һәм бурычлары

3.1. Бәйгенең максаты – белем бирүдә федераль дәүләт стандартларын гамәлгә кую чорында татар теле һәм әдәбиятын укыту методологиясен пропагандалау аша укытучыларның һөнәри компетентлылыгын күтәрү, укучыларның рухи-әхлакый үсеше, компетентлыгын тәэмин итүгә юнәлтелгән педагогик технологияләрне гамәлгә кую.

3.2. Бәйгенең бурычлары:

– татар теле һәм әдәбияты укытучыларының белем бирүдә федераль дәүләт стандартларын гамәлгә куюга әзерлеген активлаштыру;

– педагогик хезмәткәрләрнең алдынгы педагогик тәҗрибәсен туплау һәм тарату.

## IV. Бәйгене оештыручылар

4.1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

4.2. Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты;

4.3. «Мәгариф» журналы.

## V. Бәйгедә катнашучылар

Республиканың барлык мәгариф оешмаларының татар теле, әдәби уку һәм әдәбият укыту буенча башлангыч һәм төп гомуми белем программасын гамәлгә куючы укытучылар.

## VI. Бәйгенең шартлары

Бәйге читтән торып үткәрелә. Җибәрелгән материаллар Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты

Документ создан в электронной форме. № под-371/17 от 09.03.2017. Исполнитель: Гайфуллина Л.А.
Страница 2 из 6. Страница создана: 09.03.2017 16:08
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

кафедрасы, милли мәгариф лабораториясе хезмәткәрләре һәм башка белгечләр тарафыннан экспертиза узачак.

Эксперт төркем составына республикакүләм танылган татар теле һәм әдәбияты укытучылары кертелә.

Конкурста катнашу өчен материалларны shgul-79@mail.ru электрон тартмага җибәрүегез сорала.

Җибәрергә тиешле материаллар исемлеге:

1. гариза (бирелгән үрнәк буенча)

| | |
|---|---|
| Катнашучының Ф.И.О. (укытыла торган фәне адресы, элемтә өчен телефон, e-mail) | |
| Белем бирү оешмасының адресы, телефоны, e-mail | |
| Дәрес кайсы аудиториягә юнәлтелгән | |
| Тема | |

2. дәрес эшкәртмәсе (кушымтада методик комментарийларны, мәгълүмати-иллюстрацияле материалны, схемаларны, таблицаларны бирергә мөмкин).

**<u>Искәрмә.</u>**

1. Дәрес эшкәртмәсе федераль дәүләт стандартлары таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының сайтында китерелгән үрнәк программаларга нигезләнеп башкарылырга тиеш.
2. Бәйгедә моңарчы басылмаган хезмәтләрне генә җибәрүегез сорала.

Материаллар түбәндәге таләпләргә туры китереп языла: текст Times New Roman шрифтында, 14 нче кегль, текст кырлары – һәрьяктан 2 см, киңлек буенча тигезләү, абзац – 1 см, интервал – 1,5. Рәсемнәр JPG форматында бирелә.

## VII. Бәяләү критерийлары

- аннотациясе – тәкъдим ителгән дәреснең программадагы урыны һәм танып белү эшчәнлеге нинди педагогик технология яки эффектив методик алымнар нигезендә оештырылачагының ассызыклану дәрәҗәсе;
- дәрес темасының формалаштырылу дәрәҗәсе;
- дидактик максатның формалаштырылу дәрәҗәсе;
- үстерешле максатның формалаштырылу дәрәҗәсе;
- тәрбияви максатның формалаштырылу дәрәҗәсе;
- танып белүне оештыруның автор сайлаган формасы һәм методларының, эш төрләренең максатка ярашлылыгы;
- автор сайлаган педагогик технологиянең гамәлгә куелу дәрәҗәсе;
- дәрес этаплары арасындагы бәйләнеш, системалылык дәрәҗәсе;
- танып белү эшчәнлегенең мотивлаштырылу дәрәҗәсе;
- үзләштерелгән белем һәм күнекмәләрнең модельләштерелү, танып белү ысулы аерып алыну дәрәҗәсе;
- рефлексиянең оештырылу дәрәҗәсе;
- үзконтроль, үзбәя процессының оештырылу дәрәҗәсе;
- өй эшләрен бирүдә дифференциальлек принцибының гамәлгә куелу дәрәҗәсе;

Документ создан в электронной форме. № под-371/17 от 09.03.2017. Исполнитель: Гайфуллина Л.А.
Страница 3 из 6. Страница создана: 09.03.2017 16:08
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

- дәрес конспектын әзерләгәндә кулланылган чыганаклар исемлеге. Аларның актуальлелеге.

## VIII. Бәйгенең төп номинацияләре

Белем бирү процессы рус телендә алып барыла торган гомуми белем бирү оешмаларының рус төркемендә татар теле дәресе эшкәртмәсе.

Белем бирү процессы рус телендә алып барыла торган гомуми белем бирү оешмаларының рус төркемендә татар әдәбияты дәресе эшкәртмәсе.

Белем бирү процессы рус телендә алып барыла торган гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемендә татар теле дәресе эшкәртмәсе.

Белем бирү процессы рус телендә алып барыла торган гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемендә татар әдәбияты дәресе эшкәртмәсе.

Белем бирү процессы татар телендә алып барыла торган гомуми белем бирү оешмаларында татар теле дәресе эшкәртмәсе.

Белем бирү процессы татар телендә алып барыла торган гомуми белем бирү оешмаларында татар әдәбияты һәм әдәби уку дәресе эшкәртмәсе.

## IX. Бәйгенең уздырылу вакыты

Конкурс эшләре 2017 елның 10 мартыннан 27 мартына кадәр кабул ителә. 27 марттан да соң килгән материаллар бәйгедә катнашмый.

## X. Йомгаклау

6.1. Бәйгедә катнашучыларга электрон формада Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының сертификаты тапшырыла.

6.2. Җиңүчеләр Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының I, II, III дәрәҗә дипломнары белән бүләкләнә.

6.3. Уңышлы дип табылган материаллар «Мәгариф» журналында басылачак. Конкурска килгән эшләрне методик кулланма буларак бастырып чыгару планлаштырыла.

Элемтәләр өчен телефон: 89872190025 – Гөлназ Марс кызы Шакирова.

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының
2017 елның 09 мартыннан гамәлгә кергән
№ под-371/17 боерыгы белән расланды

**«Милли мәгариф: заманча татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә танып белү эшчәнлеген оештыру» республикакүләм дәрес эшкәртмәләре бәйгесенең эксперт төркеме**

1. Шәмсетдинова Рәсимә Равил кызы, филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы җитәкчесе;
2. Шәехов Марат Рәшит улы, филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының милли мәгариф лабораториясе җитәкчесе;
3. Мозафарова Мингаян Гаяз кызы, педагогия фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының милли мәгариф лабораториясе әйдәп баручы фәнни хезмәткәре;
4. Шакирова Гөлназ Марс кызы, филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты милли мәгариф лабораториясенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре;
5. Гыйләҗева Лилия Гыйлметдин кызы, филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты;
6. Һадиева Гөлнара Васил кызы, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы;
7. Нурмиева Гөлгенә Вазых кызы, Татарстан Республикасы Казан шәһәре 27 нче гимназиясенең югары квалификацияле категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы;
8. Тарханова Гүзәлия Инсаф кызы, Татарстан Республикасы Казан шәһәре 96 нчы гимназиясенең югары квалификацияле категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы;
9. Сөнгатуллина Рузилә Фәиз кызы, Татарстан Республикасы Казан шәһәре 141 нче мәктәбенең беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы;
10. Хәсәншина Резедә Гатаулла кызы, Татарстан Республикасы Чаллы шәһәренең 52 нче гомуми урта белем мәктәбенең югары квалификацияле категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы;
11. Садыйков Мидхәт Миңнәтулла улы, «Мәгариф» журналы редакторы.

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының
2017 елның 09 мартыннан гамәлгә кергән
№ под-371/17 боерыгы белән расланды

**«Милли мәгариф: заманча татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә танып белү эшчәнлеген оештыру» республикакүләм дәрес эшкәртмәләре бәйгесенең оештыру комитеты**

1. Мөхәммәтов Илдар Ринат улы, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары;
2. Бадриева Рина Ринад кызы, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты ректоры;
3. Исмәгыйлева Гөлназ Хәмзовна, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф идарәсе җитәкчесе;
4. Шәрипова Алсу Сәмигулла кызы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф бүлеге җитәкчесе;
5. Шәмсетдинова Рәсимә Равил кызы, филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы җитәкчесе;
6. Шәехов Марат Рәшит улы, филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының милли мәгариф лабораториясе җитәкчесе;
7. Мозафарова Мингаян Гаяз кызы, педагогия фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының милли мәгариф лабораториясе әйдәп баручы фәнни хезмәткәре;
8. Шакирова Гөлназ Марс кызы, филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты милли мәгариф лабораториясе хезмәткәре;
9. Хәлиуллин Марат Наил улы, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының милли мәгариф лабораториясе фәнни хезмәткәре;
10. Садыйков Мидхәт Миңнәтулла улы, «Мәгариф» журналы редакторы.

Лист согласования к документу № под-371/17 от 09.03.2017
Инициатор согласования: Гайфуллина Л.А. Ведущий консультант отдела национального образования
Согласование инициировано: 02.03.2017 18:57

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Шарипова А.С. | | Согласовано<br>07.03.2017 - 18:34 | - |
| 2 | Иванова Т.А. | | Согласовано<br>07.03.2017 - 19:24 | - |
| 3 | Исмагилова Г.Х. | | Согласовано<br>08.03.2017 - 19:32 | - |
| 4 | Мухаметов И.Р. | | Подписано<br>09.03.2017 - 09:45 | - |